КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯТМАС-ДУСАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
КАРАРЫ

29 август 2019 ел №13

Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы 2014 елның 31 нче январе 3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Кукмара районы прокурорының 2019 елның 14 июнендәге 02-01-22-2018 номерлы, ачыкланган коррупцион факторны бетерү максатыннан, норматив хокукый актны үзгәртү турындагы таләбен карап, Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2014 елның 31 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган (Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советының 2016 елның 16 декабрендәге 34 номерлы, 2018 елның 21 июнендәге 15 номерлы, 2019 елның 19 февралендәге 3 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге җирләреннән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 статьяның 11 пунктындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Ятмас-Дусай авыл җирлеге территориясен төзекләндерү һәм карап тоту Кагыйдәләре белән территориаль зоналарны яисә аларның өлешләрен өстәмә юнәлешләр буенча куллануга аерым шәһәр төзелеше таләпләре билгеләнә:».

Ятмас-Дусай авыл жирлеге башлыгы Ф.Х.Гарифуллина